СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗЕЛЕНАЯ РОША
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

«15» октябрь 2020 ел Зеленая Роща № 7

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 2 октябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге №236-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 2 октябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.7 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла торган җирлектә».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы, Совет рәисе А.А.Потапов